ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 март 2026ел № 2452

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы турында

Яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләренең 10 пункты (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы Карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру үзенчәлекләренә 1 нче кушымта), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы Карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2026 елның беренче ярты еллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативлары һәм 2026 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2025 елның 8 декабрендәге 777/пр номерлы Боерыгы, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» КП экспертиза-консультация советы тарафыннан үткәрелгән тикшеренү нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Яшь гаиләләргә торак урыннар сатып алуга социаль түләү күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативын 2026 елның беренче ярты еллыгына 126 657 сум күләмендә билгеләргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ